КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 13 февраль г.Казань № 107

2020 – 2021 елларга Татарстан Республикасы акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советларындагы һәм ревизия комиссияләрендәге Татарстан Республикасы вәкилләре турында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы икътисады өчен аеруча зур әһәмияткә ия булган Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре һәм акцияләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган акционерлык җәмгыятьләре исемлеген раслау турында» 2004 елның 8 октябрендәге ПУ-614 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 27 гыйнварындагы 31 – 36, 53, 56, 59 номерлы боерыклары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы вәкилләрен махсус хокук («алтын акция») нигезендә билгеләргә:

1 нче кушымта нигезендә акционерлык җәмгыятьләренең директорлар советына;

2 нче кушымта нигезендә акционерлык җәмгыятьләренең ревизия комиссияләренә.

2. Акционерлык җәмгыятьләренең директорлар советларында һәм ревизия комиссияләрендә Татарстан Республикасы вәкилләренең 1 нче, 2 нче кушымталарында күрсәтелгән урыннары директорлар советы һәм ревизия комиссияләре әгъзаларын сайлаганда исәпкә алынмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы вәкилләрен акцияләренең 100 проценты Татарстан Республикасы милкендә булган «Химград» акционерлык җәмгыятенең директорлар советына 3 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

4. 1 – 3 нче кушымталары нигезендә 2020 елда акционерларның еллык гомуми җыелышларын үткәргәннән һәм акционерлык җәмгыятьләрендә идарә һәм контроль органнарының яңа составын формалаштырганнан соң Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2020 елларга Татарстан Республикасы акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советларындагы һәм ревизия комиссияләрендәге Татарстан Республикасы вәкилләре турында» 2009 ел, 7 март, 164 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 13 февраль, 107 нче
карарына 1 нче кушымта

Махсус хокук («алтын акция») нигезендә акционерлык җәмгыятьләренең директорлар советларына билгеләү өчен Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеге

1. «Татспиртпром» акционерлык җәмгыяте
Песошин Алексей Валерьевич – Татарстан Республикасы Премьер-министры.

2. «Казан вертолет заводы» гавами акционерлык җәмгыяте
Зарипов Равил Хаммат улы – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе.

3. «Казаноргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте
Сабиров Ринат Касыйм улы – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе.

4. «Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционерлык җәмгыяте
Сабиров Ринат Касыйм улы – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе.

5. «Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте
Хамаев Азат Кыям улы – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе.

6. «Татхимфармпрепараты» акционерлык җәмгыяте
Садыйков Марат Наил улы – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры.

7. «Камгэсэнергострой» гавами акционерлык җәмгыяте
Аляшев Юрий Леонидович – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 13 февраль, 107 нче
карарына 2 нче кушымта

Махсус хокук («алтын акция») нигезендә акционерлык җәмгыятьләренең ревизия комиссияләренә билгеләү өчен Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеге

1. «Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте
Борзунова Ксения Геннадьевна – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының бүлек башлыгы.

2. «Казаноргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте
Габделхаков Фәнис Габделфәт улы - Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бүлек башлыгы.

3. «Камгэсэнергострой» гавами акционерлык җәмгыяте
Газизуллина Тәслия Сәлимҗан кызы – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Чаллы шәһәре территориаль бүлеге районара контроль-ревизия бүлеге башлыгы.

4. «Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционерлык җәмгыяте
Габделхаков Фәнис Габделфәт улы – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бүлек башлыгы.

5. «Татхимфармпрепараты» акционерлык җәмгыяте
Миңуллин Марсель Гомәр улы – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының бүлек башлыгы.

6. «Татспиртпром» акционерлык җәмгыяте
Тюрикова Вероника Александровна – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының бүлек башлыгы.

7. В.Д.Шашин ис. «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте
Йосыпова Сәрия Кәшибулхак кызы – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бүлек башлыгы урынбасары.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 13 февраль, 107 нче карарына 3 нче кушымта

Акцияләренең 100 проценты Татарстан Республикасы милкендә булган «Химград» акционерлык җәмгыятенең директорлар советына билгеләү өчен Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеге

Кәримов Альберт Әнвәр улы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры.

___________________________________